РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОТИНЧАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА ТИНЧӘЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14 гыйнвар 2022 ел № 1

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Яңа Тинчәле авыл җирлегендә
гражданнарның үзара салым акчаларын җыю
тәртибе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Тинчәле авыл җирлеге Уставы нигезендә, җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән Яңа Тинчәле авылында 2021 елның 22 декабрендәге 1 нче номерлы, Яңа Чынлы авылы 22 декабрендәге 1 нче номерлы карарларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Тинчәле авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРДЕ:

1. Расларга:
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Тинчәле авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе (1 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Тинчәле авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган №_____ түләүне хәбәр итү (хәбәрнамә) рәвешен (2 нче кушымта).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга һәм ТР, Буа районы, Яңа Тинчәле авылы, Ленин урамы, 28 нче йорт ТР адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.К. Мадышев

Татарстан Республикасы Буа
муниципаль районының
Яңа Тинчәле авыл җирлеге
башкарма комитетының
2022 елның 14 гыйнварындагы 1
номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Тинчәле авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Тинчәле авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына бәйсез рәвештә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр һәм алар тарафыннан тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләрдә башкарыла.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә (белдерү) бланкы гражданнарга мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән, шулай ук имза куеп тапшыру яисә почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге башкарма комитетының шәхси счетына керә.

5. Гражданнарның түләүләрен түләү физик затлар кушуы буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия оешмалар аша почта күчерүләрен (исәп-хисап оешмаларын) гамәлгә ашыруга акчалар күчерү юлы белән, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Тинчәле авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яисә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/ башкарыла.

6. Түләү фактын раслаучы документлар булып, приход касса ордеры квитанциясе, чек-ордер квитанциясе, түләү фактынераслый торган башка документлар тора.

7. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының
Яңа Тинчәле авыл җирлеге башкарма комитетының
2022 елның 14 гыйнварындагы 1 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Тинчәле авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләүне түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ
№ _______________

Түләүченең Ф.И. А.и.______________________________________________________
Адресы: ______________________________________________________________
Нигез_________________________________________________________
Сезгә_______________________ чараларын гамәлгә ашыруга бер тапкыр бирелә торган __________сум күләмендә ___________ кадәр вакытта түләргә кирәк,
киләсе реквизитлар буенча:__________________________________________________
Алучының банкы БИК _____________________________________
Сч. № _________________________________
Алучы Сч. № ________________________________________
ИНН _________________________________________
КПП _________________________________________
КБК _______________ ОКАТО __________________
Түләү билгеләнеше
________________________________________________________________________

Җитәкче_________________ _______________________________________
М.У. (имза) (имзаны киңәйтеп бирү)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Тинчәле авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча _______сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәрнамә № _________________
Түләүченең Ф.И. А.и.______________________________________________________
Адресы:
________________________________________________________________________
Алды «__» _______________ 20__ ел. _____________________________________
(түләүче имзасы)

*Искәрмә. Кисүле төпсә тутырыла һәм хәбәрнамә түләүчегә шәхсән бирелгән очракта, җирлекнең Башкарма комитетында кала.*